РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 43 2021 елның 16 июле

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2021 елның 19 февралендәге 10 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Мактау грамотасы турында яңа редакциядә» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы каршында гражданнарның зур хезмәтләрен тану, район үсешенә юнәлдерелгән шәхси эшчәнлекләре өчен бүләкләү, хезмәтне стимуллаштыру һәм Түбән Кама муниципаль районы Советының иҗтимагый тормышында күрсәткән активлык өчен бүләкләү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2021 елның 19 февралендәге 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Мактау грамотасы турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.2 пунктның дүртенче абзацында «билгеләнгән тәртип нигезендә» сүзләрен «әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Аеруча катлаулы вазыйфаи һәм хезмәт йөкләмәләрен үтәгәндә инициатива, тәвәккәллек һәм фидакарьлек, карарлар кабул иткәндә батырлык, гадәттән тыш хәлне бетергәндә кыюлык күрсәткән очракларда, Түбән Кама муниципаль районы үсешенә керткән өлеше өчен, Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы үз инициативасы буенча Мактау грамотасы белән бүләкләргә хокуклы.»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р.Метшин